Газета МБОУ «АСОШ №2»

# Пульс школы
# Мәктәп пульсы



№3
Ноябрь 2020 г.

## С днём матери!



Пусть каждая женщина
вдруг улыбнется,
Которая «мамою» гордо
зовется.
Вы столько всего в своих
деток вложили,
Что праздник сей честно
вполне заслужили!
Я мамам желаю всем
женского счастья,
Чтоб прочь уходили все
беды, напасти,
Чтоб муж и детишки вас
очень любили,
Заботу и нежность, цветы чтоб дарили.
Не важно что — розы, букетик ромашек...
Но, главное, с чувством, до самых мурашек!

### Интересно знать!

- Улитка спит 3 года.
- Самая сильная мышца в теле – язык.
- Тигры имеют полоса-тую кожу, а не только полосатый мех.
- У морской звезды нет мозга.
- Гигантский кальмар имеет самый большой глаз в мире.
- Кожа белого медведя черная. Его мех не белый, а прозрачный.

***Что может быть важнее людей, которые знают так много об этой жизни, обладают мудростью, опытом!***



### В этом выпуске:


| | |
|---|---|
| Кәҗүл белән Бәркә мажаралары | 2 |
| Серле чишмә (Әкият)<br>Укучылар иҗаты | 3 |
| “Әлифба” музее<br>Шәһәребез музейлары белән танышабыз | 4 |
| Фоторепортаж с мероприятий текущего месяца | 5 |

*Театр – яктылыкка, нурга илтә,*
*Кире юлга җибәрми, уңга илтә.*
*ГабдуллаТукай*

# Кәҗүл белән Бәркә маҗаралары

Театр елы – илнең мәдәни тормышы өчен һәм иҗтимагый аң фомалаштыру өчен бик мөһим вакыйга. Театр җәмгыять һәм мәдәният үсеше белән бик тыгыз бәйләнгән. Театр сәнгате аша, дөньяга караш, әхлакый принциплар, рухи байлык формалаша, эстетик зәвык тәрбияләнә.

Татарстан театрлары Театр елын Әтнә театры сәхнәсендә ачып җибәрде. Без дә мәктәбебез укучылары белән Габдулла Тукай исемендәге Әтнә татар дәүләт драма театры сәхнәсендә театр елы уңаеннан үткәрелгән «Театр – яктылыкка, нурга илтә» исемле фестиваль кысаларында үткәрелгән бәйгедә катнашу өчен «Кәҗүл белән Бәркә маҗаралары» театрын сәхнәләштердек.

Әлеге бәйгедә катнашу безгә җиңү алып килде. Арча районы мәктәпләре арасында үткәрелгән театрлар ярышында мәктәбебезнең «Балкыш» театр коллективы Гран-При алды һәм гыйнвар аенда үткәреләчәк фестивальдә катнашу хокукына ия булды. Әлеге чара үзебезнең мәктәп сәхнәсендә үткәреләчәк. Бу чарага да без бик теләп хәзерлек эшләре алып барабыз.

Татар театры сәнгатенә мәхәббәт уяткан өчен укытучыларыбызга бик рәхмәтлебез!

Гөлназ **МИҢЛЕБАЕВА**,
9А сыйныфы







# Укучылар иҗаты!

***Әгәр гомернең сукмакларына борылып карасаң, арада иң матуры, иң якты төсләр белән җемелдәп торганы - балачак сукмагыдыр. Чөнки ул - иң самими хисләр, уйлар белән чигелгән мәктәп чоры. Күп еллар “Мәктәп пульсы” газетасыннан аерылмавым үземнең дә балачактан китәсе килмәүдер, мөгаен. Аның шулай икәнен еллар үткән саен ныграк аңлыйсың. Иң беренче кулга каләм алып иҗат итә башлау да мәктәп чорына туры килә. Безнең укучыларыбыз арасында яңа гына каләм тибрәтә башлаган укучылар бар. Укучыларым да үзем кебек, мәктәпне яраталар, балачак газетасын үз итәләр. Аларның язмалары белән сезне дә таныштырыр вакыт җитте.***

## Серле чишмә

(*Әкият*)

Аделя **Шарбатова,** «Яшь журналист» түгәрәге

Яшәгән ди, булган ди ямьле табигать кочагына сыенып утырган бер бик матур авыл. Авыл уртасында тирә-якка нур чәчеп, могҗизалар иле булган, гыйлем йорты -мәктәп әллә кайдан балкып күренеп торган. Шушы авылда туып үскән һәр сабый әлеге гыйлем йортына килеп, шунда белем алып, олы тормыш юлына чыккан. Мәктәп елларында балалар бик еш сәяхәткә чыкканнар. Бигрәк тә табигать кочагына сәяхәт итәргә яратканнар. Алар авылга ерак түгел генә урнашкан Ямбай чишмәсенә еш экскурсиягә бара торган булганнар. Ни гаҗәп, бу чишмәнең исеме дә 2 төрле булган. Ямбай һәм Акташ. Аны Ямбайлылар «Акташ» чишмәсе дип,ә Акташлылар «Ямбай» чишмәсе дип атап йөртәләр. Бу чишмәнең суы искиткеч сихәтле,күп чирләргә дәва булган. Ә иң могҗизалысы ,ул кешеләргә үземнең көчемне бирәм; яхшы кешеләр өчен минем суым шифалы,бары тик изгелекләр генә эшләргә этәрүче, ә кара эчле тар күңелле кешеләр өчен минем суым шифасыз дип телгә килеп көйләп ага торган булган. Әбибабайлардан калган шундый бер риваять телдәнтелгә күчеп сөйләнә. Әлеге чишмә янына бер бала килгән. Шулчак чишмә телгә килеп “Син бик изге бала икән”. Киләчәктә син ил-көнгә кирәкле кеше булырсың Мин сиңа шундый көчемне бирәм. Син мәктәптә алган белемеңне һәрчак изге максатларга гына багышларсың. Синең алган белемең дә, файдалы гыйлем булыр дип кабатлган .Аның улактан агучы суында аллыгөлле нурлар уянган һәм чыннан да ул бала үсеп буйга житкәч кешеләргә бик зур изгелекләр эшләгән, белем чишмәсе булган өр яңа мәктәп тә салдырып куйган.
кйган.hыл“Ямбай”чишмәсе янына барып, үзенең шатлык-куанычлары белән уртаклаша торган була.Чишмә аңа шул изгелекләр кылуыңны дәвам ит, мин сиңа һәрчак көч биреп торам, синең ке-

Ул һәрчак туган авылына кайтып әлеге “Ямбай” чишмәсе янына барып, үзенең шатлык-куанычлары белән уртаклаша торган була.Чишмә аңа шул изгелекләр кылуыңны дәвам ит, мин сиңа һәрчак көч биреп торам, синең кебек булдыклы, мәрхәмәтле кешеләр минем иң якын дусларым дигән.

Көннәрдән бер көнне әлеге чишмәгә икенче берәү килә. Иелеп суын эчәм дигәндә генә чишмә телгә килеп: син бик тар күңелле, хөсетле, кара әчле кеше. Синең әле алган белемеңне һич тә файдалы эшкә сарыф итмисең, шуның өчен минем суым да синең сусавыңны басмас, файдасыз, шифасыз булыр дигән. Шулчак күк йөзен кара болыт каплаган, жил-давыл купкан. Чишмә аңа синең кешеләр өчен бер дә изгелекләр эшләгәнен юк,әле житмәсә,тирәюньдәгеләргә гел начарлыклар эшлисең, агачкуакларны сындырып йөрисең, бары тик синең уеңда явызлыклар гына, эти-әниеңне дә яратмыйсың дип аны бик ачулы каршы алып, озатып калган. Ә егет кайтканда бер ташка абынып кулын, аягын сындырган. Шуннан соң әлеге егет уйга калган, ничек болай булды әле бу дип озак баш ваткан. Ул үзенең кешеләргә, табигатькә карата эшләгән явызлыкларын бер-бер артлы күздән кичерән, карале, югыйсә беркем күрмәгәндә генә эшләнгән этлекләрне әлеге чишмә каян белде икән, киресенчә шуннан кайтканда житмәсә бәлә-казага тарыдым дигән .Исең китәрлек , дөньяда нинди могҗизалы көчләр дә бар икән. Югыйсә, бары тик яхшы гамәлләр генә кылып яшәргә кирәк икән дип ныклы карарга килгән.

Аделя **Шарбатова,** 9Б сыйныфы

# “Әлифба” музее

***Минем өчен тормышта ике нәрсә гомер буе могҗиза булып сакланып килде: берсе – Чишмә, икенчесе – Әлифба.***
*Г.Ахунов*

Үзенең бөек мәгърифәтчеләре, күренекле язучылары, сәнгать эшлеклеләре, тырыш һәм эш сөючән хал-кы белән данлыклы Арча ягы музейлар иле дә әле. Сүзебез бүген шуларның берсе – дөньяда бердәнбер булганы хакында.
Арча педагогия көллиятендә 1999 елда оешкан “Әлифба” музее 2001 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасы мәдәният министрлыгы музее буларак эшли. Музей үзенең фәнни эчтәлеге һәм оригиналь булуы белән аерылып тора. Бирегә килүчеләрне көнчыгыш бизәкләре белән эшләнгән гарәп графикасы хәрефләре музей эченә кадәр озатып бара.
Биредә бөтендөнья халыкларының язу системасы барлыкка килү һәм аның борынгы вакыттан алып, хәзерге көнгәчә үсешен күрсәткән бай фонды бар. Ул 1226 данә экспонаттан тора.
Бүгенге көнгә кадәр килеп җиткән иң беренче әлифбалар "Иман шарты" дип йөртелгән. Ул озак гасырлар буе үзгәрешсез кулланылган. Биредә аның шул чорда кулланышта йөргән нөсхәсе урнаштырылган.
Дөньядагы бик күп төрле алфавитлар турында гаять кызыклы материаллар тупланган монда. Күп халыклар кулланган аваз системасына корылган беренче алфавит – финикия алфавиты нөсхәсен дә күрергә була хәтта. Хәзер музейда төрле илләрдән алынган 265 төрле әлифба бар. Алар арасында әзәрбәйҗан халыклары – курд, тамин, сахир милләтләре; угро-фин халыклары – коми, мари, мордва, удмурт, манси, хант, саами, уди милләтләре; мисыр, таиланд, япон һәм башка халыкларның әлифбалары.
Музейда Әхмәтһади Максуди (1867-1941) иҗаты зур урын алып тора. Ул татар имлясын камилләштерүгә зур өлеш керткән.
Ул татар имлясын камилләштерүгә зур өлеш керткән. Биредә аның үз кулы белән язылган "Татарстан әлифбасы": "Мөгаллим әүвәл" урнаштырылган.
Бу кульязма Ә.Максудиның үз кулы белән төзелеп, тел галиме Х.Курбатов тарафыннан "Бөек зат Һади Максудиның бу кульязмасы бү-геннән Рәмзия ханым белән Сәләй туган милкенә күчә. Хәлиф Курбатов. Казан. 1997 ел, 12 март" дигән язу белән татар әлифбаларын төзүчеләр Р.Вәлитова һәм С.Вәгыйзовка тапшырыла. Шулай итеп, бу кыйммәтле кульязма музей экспонатына әверелә. Әхмәтһади Максуди әлифбаларының 50 дән артык басмасы бар.
Ә менә латин графикасы нигезендә беренче әлифбаны Г.Нугайбәк белән М.Корбангалиев төзи. Ул елларда балалар, өлкәннәр, эшчеләр, крестьяннар өчен аерым-аерым әлифбалар эшләнә.
1939 елда татар язуын кириллицага күчергәч, беренче татар әлифбасын Мөхетдин Корбангалиев һәм Габбас Сәйфуллин төзи. Бу әлифба 1964 елга кадәр хезмәт итә.
Татар әлифбасының XIX гасыр азагы һәм XX гасыр чорын чагылдырган бүлмәсендә бер почмакта Кышкар авылы мәдрәсәсе, икенче почмакта илленче еллар мәктәбенең башлангыч сыйныфы, ә өченче почмакта Рәмзия Вәлитова һәм Сәләй Вәгыйзовның эш бүлмәсе күренешләре бирелгән. “Әлифба” музееның төп нигезен дә Вагыйзов Сәләй Гата улы һәм Вәлитова Рәмзия Гыйләҗ кызының педагогик һәм иҗат эшләре тәшкил итә. Алар -
1965 елдан башлап бөтен татар мәктәпләре өчен булган әлифбаның
Галимнәр бу чор эчендә башлангыч сыйныфлар өчен 40 тан артык методик хезмәт төзеп, бастырып чыгаралар. Үзләре исән булмасалар да, бүген музейның һәр почмагыннан Рәмзия апа һәм Сәләй ага рухы бөркелә кебек.
Тагын бер бүлмәсендә дөнья халыклары әлифбалары һәм язу үрнәкләре тупланган. Алар арасында Иван Федоровның 1574 елда эшләп бастырган букваре "Азбука" да бар. Бу, әлбәттә, аның күчермәсе. Төп нөсхәсе Американың Гарвард университетында саклана икән.
Борынгы идиографик язмалардан башлап безнең эрага кадәр X гасырда кулланышта булган финикия язулары, борынгы грек, латин, гарәп һәм башка күп төрле алфавитлар белән дә танышасыгыз килсә, көллияттә урнашкан музейга килегез.
Музейга тупланган бай материалны җыюда көллиятнең тарих укытучысы Хөсәен Хәйруллин, Татарстан Берләштерелгән дәүләт музее фәнни хезмәткәрләре күп көч куйганнар. Хәзерге вакытта музей “Казан арты” әдәби-музей берләшмәсе филиалы буларак эшли. Аның белән Сания Сибгатулла кызы Камалетдинова җитәкчелек итә.

Рәсимә **Ибраева,**
«Яшь журналист» түгәрәге җитәкчесе



Рәсемдә илленче еллар мәктәбенең башлангыч сыйныфы

# Фоторепортаж с мероприятий



Вот и закончился наш лагерь. 8 ноября мы провели торжественное закрытие лагеря для каждого отряда. Ребята за это короткое время сдружились, показали свои способности и узнали много нового.




В рамках комплексных профилактических мероприятий, направленных на предупреждение распространения наркомании среди несовершеннолетних в школе были проведены тематические классные часы "Мы за ЗОЖ".



В рамках празднования Дня Народного единства в нашей школе прошла акция, в которой Молодая Гвардия раздавали ленточки с триколором прохожим и учителям с поздравлениями.



7-го ноября прошли внутришкольные соревнования по волейболу среди девочек 8-10 классов посвященный Спартакиаде школьников. Заняли: 1 место 10, 2 место 8 "А" , 3 место 8 "Б" класс. Команды наградили грамотами и памятными призами.

**Редактор** учитель татарского языка и литературы Ибраева Р.Х.
***Дизайнер - верстальщик*** Ислам Сафиуллин
***Фотокорреспондент*** Азамат Файзрахманов
***Корректор*** Ислам Габдрахманов
***Редколлегия*** Камиль Гарифуллин
Раниль Заляев

***Адрес:*** ул. Мостовая, дом 15
***Сайт школы*** https://edu.tatar.ru/arsk/sch2

# Новогодний калейдоскоп





**Редактор** учитель татарского языка и литературы Ибраева Р.Х.
***Дизайнер - верстальщик*** Ислам Сафиуллин
***Фотокорреспондент*** Азамат Файзрахманов
***Корректор*** Ислам Габдрахманов
***Редколлегия*** Камиль Гарифуллин
Раниль Заляев

***Адрес:*** ул. Мостовая, дом 15

***Сайт школы*** https://edu.tatar.ru/arsk/sch2